КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 ноябрь г.Казань № 1026

«Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт унитар предприятиесен үзгәртеп оештыру турында

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының «Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт унитар предприятиесен (алга таба – Предприятие) «Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) итеп үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Учреждениенең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы Учреждение мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора.

3. Учреждение үзгәртеп оештырылган Предприятиенең хокук дәвамчысы булып тора дип билгеләргә.

4. Учреждение эшчәнлегенең төп максаты итеп җир асты байлыкларының торышын мониторинглауны һәм дәүләт хакимияте органнарын, җирле үзидарә органнарын, юридик һәм физик затларны Татарстан Республикасы территориясендә

җир асты байлыкларының торышы һәм аның табигый һәм техноген факторлар йогынтысы белән үзгәрү дәрәҗәсе турында актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат белән мәгълүмати тәэмин итүне билгеләргә.

5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын 97 берәмлек итеп билгеләргә.

6. Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы Законда Учреждениегә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

180 көн эчендә Предприятиене үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

Учреждениенең уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә Учреждениегә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән элек Предприятиегә хуҗалык эшчәнлеген алып бару хокукында беркетелгән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне оператив идарә хокукында беркетергә.

8. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына:

180 көн эчендә Учреждениенең уставын расларга һәм аны законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

ел саен Учреждение өчен аның уставында каралган төп эшчәнлек төре нигезендә дәүләт йөкләмәсен расларга.

9. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенш, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән берлектә, Учреждениенең уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң 45 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) норматив чыгымнарны раслау турындагы карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин